УДК 792.071

*А.Р. Салихова*

# ТАТАР СӘХНӘСЕНЕҢ БӨЕК ТРАГИГЫ
## *(Мөхтәр Мутинның тууына 140 ел тулу уңаеннан)*

Статья посвящена выдающемуся театральному деятелю, актеру и режиссеру Мухтару Мутину. Его яркая индивидуальность оказала заметное влияние на развитие татарского сценического искусства. Сторонник прогресса, он многое сделал для приобщения татар к лучшим достижениям мировой культуры. Он одним из первых ставил на татарской сцене произведения западноевропейских классиков: Шекспира, Шиллера, Гейне и других. Его исполнение главных ролей в этих спектаклях оставляли неизгладимое впечатление на современников и стали образцами по-настоящему страстной, проникновенной актерской игры. Работавший в разных театральных коллективах, с разными, в том числе и русскими, режиссерами, он аккумулировал в себе актерские приемы и подходы, которые затем становились характерными для татарского актерского искусства. Творческий путь Мухтара Мутина представляет большой научный интерес. В статье анализируются его наиболее значимые актерские и режиссерские работы. Дается общая оценка его плодотворной деятельности.

**Ключевые слова:** Мухтар Мутин, актерское искусство, татарский театр, спектакль, мировая классика

This article is dedicated to the outstanding theater figure, actor, and director Mukhtar Mutin. His vibrant personality had a significant influence on the development of Tatar performing arts. A proponent of progress, he did much to introduce Tatars to the best achievements of world culture. He was one of the first to stage Western European classics on the Tatar stage, including Shakespeare, Schiller, Heine, and others. His performances of the leading roles in these productions left a lasting impression on his contemporaries and became models of truly passionate, heartfelt acting. Working with various theater companies and with various directors, including Russian ones, he honed acting techniques and approaches that later became characteristic of Tatar acting. Mukhtar Mutin's creative career is of great scholarly interest. This article analyzes his most significant works as an actor and director. A general assessment is given of his productive activity.

**Keywords:** Mukhtar Mutin, acting, Tatar theater, performance, world classics

Быел күренекле театр эшлеклесе, актёр һәм режиссёр Мөхтәр Исхак улы Мутинның тууына 140 ел тулды. Ул 1886 елның 2 гыйнварында Уфа губернасы Минзәлә өязенең (хәзер Татарстан Республикасының Актаныш районы) Такталачык авылында туа. Мөхтәр Мутин исән чагында ук легендар шәхескә әверелә. Бер дә гаҗәп түгел – бөек таланты, ялкынлы темпераменты һәм үз эшенә фидакярләрчә тугрылыгы аңа аерым бер дәрәҗә бирә, татар театр сәнгатенең башка, шулай ук һичшиксез үзенчәлекле һәм көчле вәкилләре фонында ул аерылып тора. Г. Тукай һәм Ф. Әмирханның кордашы булып, ул үзенең иҗат эшчәнлеген революциягә кадәр, татар театр сәнгате тәүге

адымнарын ясаган «милли уяну» чорында ук башлый. Мөхтәр Мутинны хаклы рәвештә тәүге профессиональ актёрларның берсе дип атарга мөмкин. Әмма ул үзен җәмәгать эшлеклесе, талантлы администратор, спектакльләр куючы режисёр буларак та күрсәтә. М. Мутин татар һәм башкорт профессиональ театрын үстерүгә зур өлеш кертә, үзенең якты индивидуальлеге белән аларга билгеле бер юнәлеш бирә һәм масштаблы итә.

Мөхтәр Мутин, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская белән беррәттән, милли сәхнә сәнгатенең романтик юнәлешен тәкъдим итә, аны хәтта татар сәхнәсенең Мочаловы дип тә йөртәләр. Аның актёрлык осталыгы формалашуда индивидуаль психологик үзенчәлекләре, киң колачлы, күләмле фикерләү рәвеше, күренешләрнең асылына тиз төшенү һәм фәлсәфи гомумиләштерүләр ясау сәләте, көчле шигъри контрастларга омтылышы зур роль уйный. М. Мутинга Шекспир масштабындагы образлар якын була, ул характерларны эреләндерә, үз карашыннан чыгып, артык дип табылган көнкүреш детальләрен алып ташлый, романтикларга хас булганча, барлык хисләрне югары күтәрә. Трагедия һәм героик драманың ялкынлы пафосын зур фикерләр һәм хисләр мәктәбе дип саный һәм татар сәхнәсендә Көнбатыш Европа классиклары Шекспир, Шиллер, Гейне һәм башкаларның әсәрләрен рәхәтләнеп куя. Шул ук вакытта ул режиссёр буларак та, төп рольләрне башкаручы буларак чыгыш ясый: Отелло, Гамлет, Карл Моор, Альманзор һ. б. Үзгә темпераменты, образларны сәнгатьчә күзаллау һәм трактовкалау үзенчәлекләре, башкарган рольләренең характеры М. Мутинны монументаль һәм героик сәнгатькә тартылган классик характердагы романтик актёрлар рәтенә куярга мөмкинлек бирә [5: 110]. Югары патетика һәм пафос, ялкынлы дәрт тулы башкару манерасы ул яшәгән һәм иҗат иткән замана рухына да туры килә.

Мөхтәр Мутинның актёрлык эшчәнлеге революциягә кадәр үк башлана. Бәләбәйдәге рус гимназиясендә укыганда ук ул һәвәскәр спектакльләрдә катнаша башлый. Аннары, Бәләбәй шәһәр училищесын һәм Уфада бухгалтерлык курсларын тәмамлап, Оренбург мөселман диния нәзарәтенә эшкә керә. Әмма анда нибары ике ел гына (1906–1908) эшли.

1908 елдан ул үзен тулаем сәхнә эшчәнлегенә багышлый. Аның репертуарында – трагик монологлар, татар шагыйрьләренең шигырьләре, мелодекламацияләр. Ул гастрольләрдә күп йөри, үзенең чыгышларына җирле театр үзешчәннәрен – һәвәскәр энтузиастларны да җәлеп итә. Соңрак, рус кызы Елизавета Шляхтинага (соңыннан ул татар һәм башкорт театрларында танылган актрисаларның берсенә әверелә) өйләнеп, аны сәхнәдә дә, тормышта да үзенең аркадашы итә. Алар тамашачылар алдында чыгыш ясаячак программаларын бергәләп әзерлиләр. Ирле-хатынлы актёрлар шагыйрь Сәгыйть Рәмиев белән бергә Урал һәм Себер буйлап гастрольләрдә йөриләр, тамашычыга «Аю», «Низамлы мәдрәсә», «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин»

спектакльләрен күрсәтәләр. Мөхтәр Мутин рус аудиториясе алдында да чыгыш ясый. Аның репертуарында Алексей Апухтинның «Акылдан язган» театральләштерелгән әсәре, шулай ук Шиллер, Шекспир, Ибсен, Гаупман әсәрләре геройларының романтик рухлы монологлары була. Татар концерты программаларында Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев шигырьләре зур урын алып тора.

1912 елда беренче мөселман актрисасы С. Гыйззәтуллина-Волжская Уфада «Нур» труппасын оештыра. Мөхтәр Мутин гастрольдә йөрүдән туктамаса да, бу коллектив белән дә актив хезмәттәшлек итә [2: 66].

1915 елдан ул Оренбургтагы «Ширкәт» труппасына күчә, анда актёр гына түгел, ә режиссёр буларак та танылу ала. «Вакыт» газетасы ул вакытта М. Мутин уйнаган «Нур» һәм «Ширкәт» труппалары эшен тәфсилләп яктырта. Аларның репертуарында татар язучыларының әсәрләреннән тыш, классик пьесалар да була: Гогольнең «Өйләнү», «Ревизор», Мольерның «Саран», Шиллерның «Юлбасарлар» әсәрләре. Соңгы пьеса М. Мутинның талант үзенчәлекләрен исәпкә алып куела. Ул анда Карл Моорны (1916) уйный. Революциядән соң ук бу роль актёр репертуарында иң якты һәм тәэсирле рольләрнең берсенә әверелә.

Октябрь революциясе, аннары Гражданнар сугышы М. Мутинның героик сәнгате үсешенең нигезенә ята. Гражданнар сугышы елларында ул Көнчыгыш фронтның 1 нче, 2 нче, 5 нче армияләре фронт труппаларында уйный. М. Мутин тамашачыларда һәрвакыт зур кызыксыну уяткан М. Гафури, З. Рәмиев, С. Рәмиев, Г. Тукай әсәрләре буенча эшләнгән әдәби-музыкаль программаларның авторы һәм башкаручысы була,

1918 ел декабренең икенче яртысында Мөхтәр Мутин Казанга килә һәм Татар драма артистлары труппасына керә. 1919–1922 елларда Мәгариф халык комиссариатының театр бүлегенә җитәкчелек итә, элеккеге Сәүдәгәрләр клубын (хәзерге рус Яшь тамашачы театры бинасы) татар театрының беренче стационар бинасы итеп үзгәртүдә актив катнаша. 1920 елның октябрендә ТАССР Халык комиссариаты каршында Беренче дәүләт татар күрсәтмә труппасы барлыкка килә, аңа татар сәхнәсенең иң яхшы көчләре җәлеп ителә. Бу труппа хәзерге Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының нигезенә ята. Элеккеге «Сәйяр» (Г. Болгарская, Ә. Синяева, С. Айдаров, Х. Колмәмәт, Камал I, Камал II) һәм «Аң» труппасы (Габитов, М. Вәлишин, Г. Айдарский, Сабитов, Ковалинский) артистларыннан оештырылган күрсәтмә труппаның баш режиссёры һәм сәнгать җитәкчесе итеп Мөхтәр Мутин билгеләнә.

Тикшеренүчеләр билгеләп үткәнчә, 1920 елларда яңа совет театры репертуарын булдыру сәясәте башлана. А.В. Луначарский тарафыннан яңа пьесаларга төп таләп куела: ул эмоциональ накал һәм пафос дәрәҗәсе буенча трагедиягә якын, әмма мелодрамадагыча яхшы тәмамлана торган (революцион көчләрнең, яңа тормышның

җиңүе, яңа дөнья барлыкка килү һ. б.) героик драма булырга тиеш. Яңа заман пьесасына куелган таләпләр каршылыклы була: югары техник өлеш (яхшы әдәби тел, камил сюжет) һәм революцион пафос театр дөньясында классик пьесаларның актив рәвештә заманчалаштырылуына китерә, аларның финаллары заманага туры китереп үзгәртелә [7: 187].

Татар драма артистлары труппасында М. Мутин иң беренче итеп Ф. Шиллерның «Юлбасарлар» романтик драмасын сәхнәгә куя, анда ул төп рольне дә үзе үк башкара. Премьера 1920 елның мартында була. Революциягә кадәрге традицияләргә тугры калып, М. Мутин үзенең спектаклен «солист һәм хор» принцибы буенча кора. Сәхнәдә Карл Моор – М. Мутин өстенлек итә. Ә аның тирәсендәгеләр барысы да юлбасарлар башлыгының фетнәчел, бунтарь рухын ачарга ярдәм итүче бербөтеннең теге яки бу дәрәҗәдә кирәкле өлешләре генә булып күренә. Карлның психологик яктан бай, шул ук вакытта романтик яктан күтәренке образы куелышның үзәген тәшкил итеп, тамашачыларны көчле темпераменты, дәрте, хисләр ташкыны, буйсынмас холкы белән тетрәндерә. Спектакльнең үзенчәлекле стилистикасында реализм һәм романтика, спектакльне тудыручының акылы һәм эмоциональ көче бергә кушыла [1: 85].

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» пьесасы буенча спектакльне М. Мутин бөтенләй башкача куя, аның премьерасы 1920 елның 7 ноябрендә була. Анда революцион көрәш темалары күтәрелә һәм яңа заман геройлары психологизм чаралары ярдәмендә күрсәтелә. Спектакльдә М. Мутин үзе реалистик, тирән эчтәлекле манерада төп рольне башкара. М.Г. Арсланов фикеренчә, Мутинның Батырханы – күп авырлыклар кичергән, күп сынаулар аша узган урта яшьләрдәге ир-ат. Ләкин сынаулар һәм авырлыклар алдында ул сыгылып төшми. Киресенчә, алар геройның ихтыярын ныгыта һәм характерын көчле итә... Шунысы кызыклы: сәхнәгә аяк баскан мизгелләреннән үк Мутин – Карл Моор һәм Фердинанд (Шиллерның «Юлбасарлар»ы, «Мәкер һәм мәхәббәт»е) кебек рольләре белән тамашачыларга яхшы таныш романтик герой – бөтенләй яңа, сыналмаган юлдан бара. Ул үз героен романтиклаштырмый да, гадәттән тыш пьедесталга да менгерми, ә аны яралардан хәлсезләнгән, юл йөреп арыган, гаиләсен һәм якыннарын сагынган гади кеше итеп күрсәтергә тырыша [1: 94–95]. Спектакль зур кызыксыну уята һәм матбугатта аның турында бик күп языла.

Рус классикасы буенча куелышлар арасында Мөхтәр Мутин катнашындагы «Ревизор» спектакле тамашачылар арасында аеруча уңыш казана. Театр тәнкыйте спектакльне сокланып каршы ала. Ул «Ревизор»ның бик тә вакытлы куелуын һәм, беренче чиратта, М. Мутин тарафыннан Городничий образының дөрес аңлатылуын билгеләп үтә. «Ул уенның башыннан башлап табигый вә дөрес тон алып, шуны ахырына кадәр дәвам иттерде. Аның дикциясе бик иркен, һәр адымы саналган иде. Мутин чыннан да бу роль турысында күп эшләгән,

күп баш ваткан булырга кирәк... Городничий ролен артистның төп рольләренең берсе итеп исәпләргә ярый» [3].

Г. Коләхмәтовның «Ике фикер» пьесасы буенча куелган спектакльдә Давыт роле – М. Мутинның иҗади казанышларыннан берсе. Әсәр 1905 елда ук татар драматургиясе өчен бөтенләй яңа стилистик яссылыкта языла. Аның сәнгатьчә структурасында чынбарлыкны көнкүреш-психологик планда сурәтләү һәм аерым образларның символик-аллегорик чишелеше гаҗәеп рәвештә яраша, кушыла һәм реализм методы белән билгеләнгән үзенчәлекле бергәлек барлыкка китерә. Тормыш дөреслеге кануннары һәм монтажлау алымнары, яңа барлыкка килгән кинематограф агымнары спектакльнең иҗатчылары алдына гадәти булмаган бурычлар куя.

Татар сәхнәсенең бөек инглиз драматургы В. Шекспир мирасын үзләштерүе аеруча игътибарга лаек. 1920 елларда аның пьесалары белән кызыксыну сизелерлек арта. Моның җитди сәбәпләре дә була, чөнки чор өчен характерлы яңа актёрлык техникасын эзләү Шекспир поэтикасында һәм Шекспир театральлегендә салынган юнәлешләр белән кисешә [4: 3]. Яшь совет театры Шекспир образлары өчен актуаль булган режиссёрлык һәм актёрлык трактовкаларын бик тырышып эзли.

В. Шекспирның 1921 елда Зур рус драма театры режиссёры Ю.В. Соболев куйган «Гамлет»ы шушы процесслар агымына кушыла. Татар сәхнәсендә бөек драматургның трагедиясе гадәттән тыш көчле һәм бербөтен шәхеснең дәртле, мавыктыргыч гаделлек өчен көрәше тарихы буларак кабул ителә. Спектакльне кискен романтик контрастларга корып, драматизмны куертып һәм бер ноктага туплап, герой халәте, өмет һәм өметсезлекләре фаҗигасын соң чиккә җиткереп, ул акыл, гаделлекнең һичшиксез тантана итәчәге турындагы фикерне бөтен спектакль аша үткәрүгә ирешә. «Гамлет»ның татар сәхнәсендә куелуы классик әсәрләргә принципиаль яңача якын килүне раслый. «Тәвәккәл», традицион «газап чигүче» принцка караганда Ф. Шиллерның «Юлбасарлар»ындагы Карл Моорга күбрәк якын торган Гамлет (М. Мутин) – Шекспир пьесасын актив интерпретацияләү һәм фаҗигалылыкны новаторларча – актив, иҗади һәм тормышны раслаучы башлангыч буларак – аңлау нәтиҗәсе. Бунтарь, протест белдерүчән, фетнәчел Гамлетны актёр һәм режиссёр ил тарихындагы кризислы, тамырдан борылыш мизгеле, үз заманының яңгырашы булган вакыйгалар белән бәйли [2: 106].

Бу сезонда шулай ук В. Шекспирның икенче үлемсез трагедиясе – «Отелло» буенча спектакль (төп рольдә Мөхтәр Мутин) дә зур уңыш белән бара. М. Мутинның Отеллосы – сәләтле, саф, ышанучан, бөек эшләргә һәм зур хисләргә сәләтле, көчле акылга һәм киң фантазиягә ия кеше.

Шулай итеп, 20 нче еллар башында М. Мутин татар театрында аерым урында тора: ул җитәкчелектә эшләп кенә калмый, бәлки иң

яхшы һәм үзенчәлекле актёрлар арасына керә һәм трагик шартлардагы романтик герой буларак үз урынын таба.

1926 елда, татар театрының 20 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан, М. Мутинның, беренчеләрдән булып, С. Гыйззәтуллина-Волжская, З. Солтанов, Б. Тарханов, К. Шамил, К. Тинчурин белән бергә «Татарстан АССРның атказанган артисты» дигән мактаулы исемне алуы бер дә гаҗәп түгел. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: М. Мутин әлеге юбилейны әзерләүдә актив катнаша һәм 2003 елда кабат нәшер ителгән «Татар театры» (1926) китабын төзүче-авторларның берсе була [6].

20–30 нчы елларда Казанда мәдәни тормыш шау-шулы һәм бик тотрыксыз була. Мөхтәр Мутин да мәдәниятнең төрле өлкәләрендә эшләргә мәҗбүр була. Ул төрле театр коллективларында (Мәскәүдә, Уфада, Буада) спектакльләр куя һәм сәхнәдә уйный, Татарстан радиокомитетында диктор һәм режиссёр булып эшли, «Булат батыр» дип аталган беренче татар кинокартинасын эшләүдә катнаша. Мөхтәр Мутин башкорт театрына бик күп көчен һәм энергиясен бирә. Актёр буларак кына түгел, режиссёр, педагог, оештыручы буларак та. 1922–1924 елларда баш режиссёр вазифасында Башкорт драма театрын җитәкли. Озак еллар дәвамында ул бу коллектив белән тыгыз элемтәдә тора, вакыт-вакыт башкорт сәхнәсенә әйләнеп кайта һәм анда истә калырлык якты образлар галереясын тудыра.

Кызганычка каршы, бу бөек актёрны да фаҗигалы язмыш көтә. Сәхнәдәге күп кенә көрәштәшләре кебек, Мөхтәр Исхак улы да Сталин репрессияләре корбаны була. Ул 1937 елның 24 апрелендә кулга алына. 1937 елның 19 сентябрендә СССР Югары суды Хәрби коллегиясе тарафыннан троцкизмлыкта гаепләнә һәм 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Бик күп авырлыклар кичергәннән соң, 1941 елның 3 июнендә ул Магадан өлкәсендә лагерьда вакытта дөнья куя. Мөхтәр Мутин үлгәннән соң 1963 елның 1 августында реабилитацияләнә.

Легендар трагик актёр шәхесе һәм аның милли сәхнә сәнгатен торгызуга керткән өлеше халкыбыз хәтерендә мәңге сакланыр. Тарихи гаделлекнең таләбе шундый.

**Әдәбият**

1. *Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1906–1941). Казань, 1992.

2. *Арсланов М.Г.* Тылсым. Татар театры: режиссёрлар һәм драматурглар. Казан: Мәгариф, 2008. 287 б: фот. б-н.

3. *Кәрам Г.* Татар сәхнәсендә «Ревизор» // Татарстан хәбәрләре. 1921. 14 февраль.

4. *Ким А.К.* Образы Шекспира на советской сцене 1920–1930-х годов: к проблеме актерской техники в режиссерском театре: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. СПб., 2012.

5. *Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. Казань, ИЯЛИ, 2016. 360 с.

6. Татар театры (1906–1926) = Татарский театр (1906–1926). Казан: Мәгариф, 2003. 269 б.

7. *Шалаева Н.В.* Репертуар, пьеса, сюжет: становление советского театра (1920-е гг.) // Теория и практика общественного развития. 2015. № 21. С. 186–189.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Салихова Айгуль Рустэмовна,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник Центра искусствоведения Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*aygul.salikhova.68@mail.ru*